СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

01.03.2018 с. Верхний Услон №36-171

Югары Ослан авыл җирлеге Советының «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымын түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 26.09.2017 ел, №31-142 карарына үзгәрешләр кертү турында

Югары Ослан районы прокурорының 09.01.2018 ел №02-07-02 протестын караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1.Югары Ослан авыл җирлеге Советының «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымын түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 26.09.2017 ел, №31-142 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир участогы (өлеше) булган салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы өчен генә бирелә дип билгеләргә;

1.2. Әлеге карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым түләүчеләр - физик затлар, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге башлыгы М.Г.Зиатдинов